

# Әфганстан йөрәк ярасы

Баландыш авыл

тан, исемең шигъри синең,
сихри, кыя, таш-тауларың!
дуслык бурычын үтәр өчен
итте бик күп якташларым...



***Бу альбом  батыр йөрәкле, куркусыз, дөньяга матур тормыш, азатлык китерүчеләр , коточкыч афәтне үз күзләре белән күргән, аның эчендә кайнаган, гомерендә мылтык та тотып карамаган килеш, яңгыр кебек яуган кургаш астында исән калырга, кулсыз-аяксыз калган иптәшләренең өзгәләнүләрен ишетергә, үз кулында җан биргән иптәшенең соңгы амәнәтен үтәргә көч тапкан авылымның әфган сугышы батырларына багышлана.***




***Әфганстан.***
***Каян гына килеп керде соң безнең телебезгә***
***бер үк вакытта сихри дә, ят та, дәһшәтле дә булган бу сүз?***
***Килеп керде дә, барыбызны да сискәндереп,***
***сагаерга мәҗбүр итте, аналарның төн йокысын качырды,***
***илгә кургаш табутлар кайтарды.***




***Әфганстан. Күпләрне тетрәндергән сүз бу.***
***Леонид Брежнев Әфганстанга***
***совет гаскәрләре кертелү турындагы хәбәрне***
***Үзәк телевидение буенча***
***1979 нчы елның 25 нче декабрендә игълан итте.***

***Фәкать 1988 нче елның 15 нче маенда гына***
***чит илдәге гражданнар сугышыннан***
***совет гаскәрләре чыгарыла башлады һәм,***
***ниһаять, 1989 нчы елның 15 нче февралендә соңгы***
***совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыкты***

**Әфганстанның шомлы жилләре безнең Баландыш авылын да урап үтмәде.**

**Безнең авылда туып-үскән 8 егеткә дә**

**ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булып,**

**гомерләрен куркыныч астына куеп**

**ут астында йөрергә,**

**дары исен иснәргэ туры килә.**



*Рөстәм абый Бурганов 1960 нчы елда*
*Баландыш авылында туа.*
*1978-1980 нче елларда армия сафларында,*
*Әфганстанда Кабул,*
*Асадабад шәһәрләрендә*
*шофер булып хезмәт итә.*
*Әфганстан җиренә аяк баскан*
*беренче авылдаш ул.*



***Рифнур абый Насибуллин -төгәл,
үз максатына ирешүчән
һәм бик тырыш кеше. Ул 1959 нчы елда
Урта Мишә авылында туа.
Аңа да Әфган ачысын татырга
туры килгән. 1982-1983 нче елларда
Әфганстанда Джабаль- Уссарадж
шәһәрендә хезмәт итә ул.***



***Фазыйх абый Нуриев 1960 нчы елда***
***Баландыш авылында туа.***
***Аңа да армия хезмәтен***
***Әфган җирендә үтәргә насыйп була.***
***Бик күп сугышчан заданиеләрдә***
***катнаша.***



Әсгать абый Мухаметшин 1966 нчы елда
Баландыш авылында туа.
1984 нче елның 21 нче октябрендә армия сафларына алына.
Хәрби әзерлек уткәннэн соң кайнар нокталарның берсенә жибәрелә.
Әфганстанның Шиндант шәһәрендә танкист булып хезмәт итә.



***Рузил абый Хазиев 1967  нче елда***
***Баландыш авылында туа.***
***1985 нче елнын 8 нче маенда армия***
***сафларына алына. Хабаровский***
***әлкәсенең***
***Благовещенск шәһәренә барып урнаша.***
***3 ай хезмәт иткәннән  соң Әфганстанга***
***җибәрелә. Анда ул Керки шәһәрендә***
***десант,***
***чик сакчысы вазифасын ути.***



***Ильдар абый Гилязиев 1968 нче елда***
***Баландыш авылында туа.***
***1987-1989 нчы елларда Әфганстанда***
***Герат, Кандагар шәһәрендә пулеметчы хезмәтен үти.***



Райнур абый Исмагилов 1968 нче елда
Баландыш авылында туа.
1986-1988 нче елларда
Әфганстанда Джелалабад шәһәрендә
хәрби пехота машинасында хезмәт ит



*Ильнур абый Шарипов 1968 нче елда*
*Баландыш авылында туа.*
*1986 елның язында армия сафларына*
*алына.*
*Ашхабад шәһәрендә хәрби әзерлек*
*уткэннэн сон Әфганстан демократ*
*Республикасына жибәрелә.Кандагар*
*шәһәрендә*
*десант гаскәрендә хезмәт итә*




***Алар барысы да тау-таш арасында,***
***үзенчәлекле климат шартларында***
***сугышның дәһшәтен,***
***бөтен авырлыгын***
***һәм газапларын, кайгы-хәсрәтләрен***
***үз җилкәләрендә татыган баһадирлар.***
***Авылдашларыбыз әлеге сугышта***
***зур батырлык, чын рухи түземлек үрнәкләре күрсәткәннәр.***

**Мәңгелек дан сезгә, җиребезгә азатлык китерүчеләр!**

**Әфганстан!**
**Шушы бер кирәкмәгән сугыш аркасында**
**күпме гөнаһсыз, әле яшәргә дә өлгермәгән**
**егетләребез иңнәренә автоматларын асып,**
**тау-таш арасында әфган халкының тынычлыгын яклап үз гомерләрен бирделәр.**
**Күпме гаилә ут эчендә яшәде.**
**Купме ананың газиз баласы өчен кайнар куз яшьләре чишмә булып акты.**
**Шушы сугыш аркасында Татарстан 257 кешесен югалтты, боларның күпмесе үз районыбызның батыр йөрәкле кыю егетләре.**






Күңелләрдә тирән эзләр кала
Бу гомердә узып барыштан.
Егетләр дә илем дастанына
Өлеш кертә яңа тарихтан.

Һәр кешенең дәрт-хыяллар
белән
Сугарылган була юл башы.
Матур көннәр, тыныч еллар
гына
Булсын иде гомер юлдашы.

Туган илне саклау ирләр эше
Сез акларга тиеш өметне.
Мактау белән искә ала
һәркем
Ил сакчысы дигән егетне…

***Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын,***
***яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен,***